**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23нчейорт
Лаеш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023елның 25 гыйнвары 107 номер

# КАРАР

**«Баланы (балаларны) тәрбияләүче опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга акчалата түләүне билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүсез башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле акчалата бүләкләүне түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге 4484 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында.**

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гаилә кодексы (2022елның 19 декабре редакциясе) нигезендә, «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, карар бирәм:

1. «Баланы (балаларны) тәрбияләүче опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга акчалата түләүне билгеләү һәм түләү, шулай ук үз вазыйфаларын түләүсез башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле акчалата бүләкләүне түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге 4484 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазифаларын**
**башкаручы** **А.Г.Карсалов**